КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 октябрь

г.Казань

№ 973

«Коммерциячел булмаган оешмаларга «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыру һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 29 март, 161 нче карары белән расланган һәм «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Коммерциячел булмаган оешмаларга «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыру һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 29 март, 161 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 25 июль, 579 нчы; 2014 ел, 21 июль, 520 нче; 2015 ел, 1 июнь, 393 нче; 2018 ел, 14 июнь, 480 нче, 2018 ел, 29 сентябрь, 887 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәгә, 3 бүлекнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Конкурс үткәрүне оештыру-техник яктан тәэмин итүне  Коммерциячел булмаган оешмаларга «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыру һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе нигезендә конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә субсидия бирелгән оешма (алга таба – Оешма) башкара.  Оешма түбәндәгеләрне тәэмин итә:».

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 30 октябрь, 973 нче
карары белән расланды

Коммерциячел булмаган оешмаларга «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыру һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде.

Тәртип Татарстан Республикасы Президентының «Ел җитәкчесе» Республика иҗтимагый конкурсы турында» 2002 елның 26 февралендәге ПУ–121 номерлы Указы нигезендә үткәрелә торган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсыноештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү максатларында коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели, аның нәтиҗәләре буенча ел саен Татарстан Республикасы икътисадының төрле тармакларында һәм өлкәләрендә үз эшчәнлеген алып баручы, үз эшендә югары нәтиҗәләргә ирешкән һәм алар җитәкләгән коллективлар белән бергә Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше бурычларын хәл итүгә сизелерлек өлеш керткән иң яхшы предприятиеләр (оешмалар) җитәкчеләре билгеләнә.

2. Субсидия тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет акчаларын алучы буларак Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына (алга таба – вәкаләтле орган) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидия субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү планлаштырыла торган айның 1 көненә түбәндәге таләпләргә туры килә торган дәүләт (муниципаль) учреждение булмаган коммерциячел булмаган оешмага (алга таба – сайлап алуда катнашучы) бирелә:

сайлап алуда катнашучының салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнмәгән йөкләмәләре булырга тиеш түгел;

сайлап алуда катнашучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне кире кайтару буенча, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты каршында акчалата йөкләмәләр буенча кичектерелгән (җайга салынмаган) бурычлары булырга тиеш түгел;

сайлап алуда катнашучы үзгәртеп кору, бетерү процессында булырга тиеш түгел, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридки зат булган сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры турында мәгълүматлар юк;

сайлап алуда катнашучы чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып дәүләт яки территория торган, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен (офшор зоналар) үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирүне күздә тотмый торган чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында дәүләт яки территория булып торган, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган счалым салуның ташламалы салым режимын;

сайлап алуда катнашучы Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алырга тиеш түгел;

сайлап алуда катнашучы үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра;

сайлап алуда катнашучы алдагы өч ел дәвамында хезмәткәрләрнең минималь хезмәт хакы күләменнән дә ким булмаган хезмәт хакы дәрәҗәсен хуплый.

4. Субсидия алучыны сайлап алу тәкъдимнәр соратып алу юлы белән үткәрелә. Сайлап алу сайлап алуда катнашучылар тарафыннан сайлап алуда катнашу өчен җибәрелгән тәкъдимнәр (гаризалар) нигезендә, сайлап алуда катнашучының сайлап алу критерийларына һәм сайлап алуда катнашуга тәкъдимнәр (гаризалар) керүнең чиратлылыгына туры килүеннән чыгып үткәрелә.

5. Субсидия алу өчен сайлап алуда катнашучы вәкаләтле органга түбәндәге документларны үз эченә алган тәкъдим (гариза) тапшыра:

вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча гариза;

гамәлгә кую документларының күчермәләре;

сайлап алуда катнашучы җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

сайлап алуда катнашучы җитәкче тарафыннан расланган, субсидия акчалары исәбеннән гамәлгә ашыру планлаштырылган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын (алга таба – «Ел җитәкчесе» конкурсы) оештыру һәм үткәрү өчен чыгымнар сметасын, аларның күләмен нигезли торган мәгълүматны (чыгымнар нормативлары, статистик мәгълүматлар, коммерция тәкъдимнәре һәм башка мәгълүмат күрсәтеп, үз эченә тиеш планлаштырылган чыгымнар юнәлешләре калькуляциясен алган финанс-икътисадый нигезләмәне теркәп;

уңай имидж формалаштыруга, җәмәгатьчелектә танылуга һәм үзебезнең иң яхшы менеджерлар – предприятие (оешма) җитәкчеләре, сәнәгатьчеләр, эшмәкәрләр тәҗрибәсен таратуга ярдәм итүче чараларны үткәрүдә катнашучы тәҗрибәсе турында сайлап алуда катнашучы җитәкчесе тарафыннан имзаланган белешмә;

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 3 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында сайлап алуда катнашучы җитәкчесе имзалаган белешмә (ирекле формада);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган тәкъдим (гариза), тиешле сайлап алу белән бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастыруга (урнаштыруга) ризалык.

Документлар сайлап алуда катнашучы тарафыннан кәгазьдә тапшырыла.

Кәгазьдә бирелгән барлык документлар да төгәл бастырып чыгарылырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр, сайлап алуда катнашучы – вәкаләтле зат имзасы белән расланган һәм мөһере белән беркетелгән төзәтмәләрдән тыш, рөхсәт ителми. Кәгазьдә бирелгән тәкъдимнәрнең (гаризаларның) барлык битләре, сайлап алуда катнашучы вәкаләтле затның имзасы белән таныкланырга һәм әйләнештә тәкъдим (гариза) әйләнешендә гомуми саны күрсәтелеп, мөһер (мөһер булганда) белән беркетелгән булырга тиеш.

Тәкъдим (гариза) документларда тупас төзәтмәләр, таплар, су агу, шулай ук шрифтның аңлашылмавы ачыкланган очракта теркәлү үткән көнне кире кагыла.

6. Сайлап алуда катнашучы үз теләге белән вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазенең күчермәсе;

салым органында исәпкә куюе турында таныклык күчермәсе;

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле үтәлмәгән йөкләмәләр булмавы турында салым органы тарафыннан бирелгән белешмә ;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Сайлап алуда катнашучы әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, вәкаләтле орган әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

7. Вәкаләтле орган сайлап алуны үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://mpt.tatarstan.ru/) сайлап алу турында белдерү урнаштыра. Тәкъдимнәр (гаризалар) кабул итү, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында (https://mpt.tatarstan.ru/) сайлап алу турында игълан урнаштырылган көннән алып, календарь көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә башкарыла.

Сайлап алуны үткәрү турында игълан үз эченә ала:

сайлап алу үткәрү вакытлары (сайлап алуда катнашучылар тәкъдимнәрен (гаризаларын) тапшыру (кабул итү) башлану (тәмамланы) датасы һәм вакыты);

субсидия бирү максатлары;

субсидияләр бирү нәтиҗәләре, мәгънәләре килешүләрдә билгеләнә торган матди һәм матди булмаган объектлар һәм (яки) тиешле проектлар нәтиҗәләренә ирешкәндә (мондый детализация мөмкинлеге булганда) алырга планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр өлешендә күрсәткечләрне дә кертеп, нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны уздыру тәэмин ителә торган сайт;

әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата критерийлар;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелә торган тәкъдимнәр (гаризалар) һәм тәкъдимнәр (гаризалар) формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне бирү тәртибе;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) кире алу тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) кире кайтару тәртибе, шул исәптән сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) кире кайтару өчен нигезләр, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәренә (гаризаларына) үзгәрешләр кертү тәртибе;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) карау һәм бәяләү кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алу үткәрү турында игълан нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый тәкъдим итүнең башлану һәм тәмамлану вакыты;

субсидия бирү турында килешүгә кул кую вакыты;

субсидия алучыны килешү төзүдән читләштерелгән дип тану шартлары;

сайлап алу нәтиҗәләрен вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру датасы.

8. Вәкаләтле орган:

тәкъдимнәр (гаризалар) кергән көнне аларны керү чираты тәртибендә журналга терки, аңа сан сугылырга, шнурланырга һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш. Тәкъдимне (гаризаны) теркәгәндә номерда аның керү датасына һәм вакытына күрсәтмә булырга тиеш;

тәкъдимнәр (гаризалар) кабул итү тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә тапшырылган документларны сайлап алу критерийларына һәм әлеге тәртип таләпләренә туры китереп карый һәм сайлап алуда катнашучыга субсидияләр бирү турында карар кабул итә, аңа карата субсидия бирү (алга таба – субсидия алучы) яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә. Субсидия алучы сайлап алуда катнашучылар арасында сайлап алу критерияләре һәм тәкъдимнәр (гаризалар) керү чираты нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

Сайлап алуда катнашу өчен бер генә тәкъдим дә (гариза) тапшырылмаган очракта, сайлап алу булмаган дип таныла.

Тәкъдимнәр (гаризалар) биш баллы шкала буенча сайлап алуның һәр критерие буенча (1дән 5кә кадәр) вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча тавыш бирү кәгазенә баллар кертү юлы белән бәяләнә. Сайлап алуның билгеләнгән критерийларына җавап бирә торган берничә тәкъдим (гаризалар) булган очракта, субсидия уңай имидж формалаштыруга, илебездәге иң яхшы менеджерлар – предприятие (оешма) җитәкчеләре, сәнәгатьчеләр, эшкуарлар тәҗрибәсен җәмәгатьчелеккә тануга һәм таратуга ярдәм итүче чараларны оештыру һәм үткәрүдә иң зур тәҗрибәгә ия булган, әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы алтынчы абзацы

нигезендә тапшырылган документ белән расланган, шулай ук бирелгән тәкъдимнең (гаризаның) чиратлылык тәртибе буенча өстенлеге булган катнашучыга бирелә.

9. Тәкъдимнәрне (гаризаларны) караганда вәкаләтле орган аларның әлеге Тәртипнең 3 һәм 5 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә һәм сайлап алуның түбәндәге критерийларына таяна:

уңай имидж формалаштыруга, иҗтимагый тануга һәм илебездәге иң яхшы менеджерлар – предприятиеләр (оешмалар) җитәкчеләре, сәнәгатьчеләр, эшмәкәрләр тәҗрибәсен таратуга ярдәм итүче чаралар оештыру һәм уздыру тәҗрибәсе булу өч елдан да ким булмаска тиеш.;

әлеге Тәртипнең 18 пунктында каралган чыгымнарның финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган юнәлешләренә сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдим ителгән «Ел җитәкчесе» конкурсын оештыруга киткән чыгымнар сметасының туры килүе;

федераль законнар нигезендә сайлап алуда катнашучы Татарстан Республикасы территориясендә субсидия алу хокукына сайлап алу игълан ителгәнчегә кадәр өч елдан да ким булмаган вакыт эчендә теркәлгән.

10. Сайлап алуда катнашучы сайлап алу вакыты чыкканчы тәкъдимне (гаризаны) теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы.

11. Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуда катнашучының тәкъдимнәрен (гаризаларын) кире кагу һәм конкурсантларны бәяләү өчен нигез булып тора:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдим ителгән тәкъдимнәр (гаризалар) һәм документларның сайлап алу үткәрү турында игъланда билгеләнгән таләпләргә (гаризаларга ) туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы биргән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турында мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдимнәр (гаризалар) бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң тәкъдимнәр (гаризалар) бирү.

12. Сайлап алуда катнашучы җитешсезлекләрне бетерергә һәм сайлап алу өчен бирелгән вакытта төзәтелгән документларның тулы пакеты белән кабат гариза бирергә хокуклы. Шул ук вакытта төзәтелгән тәкъдим (гариза) документлар пакеты белән аларның кабат кергән көнендә, тәкъдимнәр (гаризалар) керү чираты тәртибендә теркәлә.

13. Тәкъдимнәр (гаризалар) түбәндәге адрес буенча карала: Казан ш., Островский ур., 4 йорт.

14. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча тәкъдимнәр (гаризалар) соратып алуны үткәрү беркетмәсе Төзелә, анда шул исәптән түбәндәге мәгълүмат чагылдырыла:

тәкъдимнәрне (гаризаларны) карау датасы, вакыты һәм урыны;

сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат, тәкъдимнәр (гаризалар) каралды;

сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат, тәкъдимнәр (гаризалар) кире кагылган сәбәпләр, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турында игъланнар нигезләмәләре күрсәтелгән, аларга мондый тәкъдимнәр (гаризалар) туры килми;

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

Тәкъдимнәр соратып алу беркетмәсе вәкаләтле орган тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында (https://mpt.tatarstan.ru/) сайлап алу тәмамланганнан соң 14 календарь көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

15. Субсидияләр бирү килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типик форма нигезендә, субсидия алучы игълан ителгәннән соң ике эш көне эчендә имзалана.

Субсидия алучы субсидия бирү турындагы килешүгә билгеләнгән сроктата кул куймаса, субсидия алучы килешү төзүдән читләштерелгән дип санала.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

аны күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе;

чараны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар төрләре;

субсидияләрне (субсидия калдыкларын) кайтару тәртибе һәм сроклары;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, вәкаләтле органга моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә илешүнең яки килешүне өзүнең яңа шартларын килештерү шартлары;

субсидия алучының һәм субсидия бирү турында килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча подрядчылар (башкаручылар) булган затларның вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә финанс контролен гасәлгә ашыруга, шулай ук мондый нигезләмәләрне килешүгә кертү турында ризалыгы;

субсидия акчсы исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш;

Кирәк булганда, вәкаләтле орган һәм субсидия алучы субсидия бирү турында килешүгә өстәмә килешү яки килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

16. Аны алучыга субсидияләр бирү нәтиҗәсе булып, республика икътисадының төрле тармакларындагы һәм тармакларындагы предприятие һәм оешмаларның агымдагы елда иң яхшы җитәкчеләрен билгеләү һәм килешүдә билгеләнгән түбәндәге күрсәткечләргә ирешү максатыннан, «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү тора:

«Ел җитәкчесе» конкурсы номинацияләре саны;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, иҗтимагый һәм башка оешмаларның «Ел җитәкчесе» конкурсында катнашучылар буенча тәкъдимнәр әзерләүгә җәлеп ителгән саны;

«Ел җитәкчесе» конкурсында катнашучыларга тәкъдимнәр әзерләүгә җәлеп

ителгән муниципаль районнар һәм шәһәр округлары өлеше;

«Ел җитәкчесе» конкурсы номинантлары булган җитәкчеләр саны;

«Ел җитәкчесе» конкурсы лауреатлары саны;

узган ел үткәрелгән «Ел җитәкчесе» конкурсы лауреатлары турында бастырыла торган китап нөсхәләре саны.

17. Субсидия алучы вәкаләтле органга түбәндәгеләрне тапшыра:

субсидияләр бирү елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендәне форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап;

хисап кварталыннан соң килүче көннең бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында хисап.

18. «Ел җитәкчесе» конкурсын оештыру һәм уздыру өчен чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидияләр бирелә торган юнәлешләр:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Ел җитәкчесе» конкурсы сайтын яңартуга һәм тотуга чыгымнар;

узган ел үткәрелгән «Ел җитәкчесе» конкурсы лауреатлары турында истәлекле китап чыгаруга чыгымнар;

«Ел җитәкчесе» конкурсы лауреатларын бүләкләү тантанасын әзерләүгә чыгымнар (бүләкләү тантанасына чакыру билетлары һәм аларга вкладышлар әзерләү һәм әзерләү, бүләкләү тантанасы өчен утырту схемаларын типографик әзерләү, бүләкләү тантанасы өчен видеороликлар, залны бизәү өчен чәчәк бәйләмнәре һәм чәчәк композицияләре, залны арендалау, тавыш һәм ут техникасы, бәйрәм ашы, лауреатларның бүләкләү атрибутикасын әзерләү (билгесе, таныклык, футляр, лауреат дипломы));

«Ел җитәкчесе» конкурсын оештыруда һәм үткәрүдә катнашучы хезмәткәрләрнең, шулай ук әлеге эшләрне башкару өчен билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителә торган башка затларның хезмәт өчен түләү чыгымнары;

субсидия алучы тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү;

транспорт чыгымнары;

телефон һәм электрон элемтә өчен түләү;

финанс оешмалары хезмәтләре өчен чыгымнар;

канцелярия һәм оештыру техникасы өчен чыгым материаллары сатып алу.

19. Бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + ... + З_n,$$

монда:

$З_1, З_2, ..., З_n$ – әлеге Тәртипнең 18 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар суммасы, алар чагыштырма базар бәяләренең (базарны анализлау) вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә, ул шундый ук товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турында, шул исәптән оештыручы-

җитештерүчеләрнең бәяләре турында, дәүләт статистикасы органнарында булган бәяләр дәрәҗәсе турында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта, «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җитештерүчеләр һәм тәэмин итүчеләрнең рәсми сайтларын да кертеп.

20. Вәкаләтле орган субсидияне Россия кредит оешмасында ачылган субсидия алучының исәп-хисап счетына килешү төзелгән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча күчерә.

21. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртипнең 3 һәм 5 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

22. Субсидия алучы тарафыннан аны кире кайтару турында карар кабул ителгәннән соң 30 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кайтарылырга тиеш:

вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча субсидия биргәндә билгеләнгән субсидия бирү шартларын бозу;

субсидия алу өчен дөрес булмаган (тулы булмаган) белешмәләр һәм документлар тапшыру;

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнар турында хисапларны, субсидия бирү нәтиҗәләренең билгеләнгән срокларда ирешелүләре турында хисап тапшырмау;

субсидия чараларын максатсыз куллану;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү.

Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу фактлары ачыкланса, субсидия алучы вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә тиешле акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылган очракта – тулы күләмдә;

субсидияләрдән файдалану һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшырмаган очракта – тулы күләмдә;

субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелмәгән мәгънәсе өчен – тулы күләмдә;

субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозган очракта – тулы күләмдә;

субсидия акчаларыннан максатчан файдаланмау ачыкланган очракта – максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган субсидия күләмендә;

23. Килешүдә каралган очракларда, хисап финанс елында кулланылмаган субсидияләрнең калдыклары, хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр

субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемено кире кайтарылырга тиеш.

24. Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 22 һәм 23 пунктларында күрсәтелгән субсидияләрне кире кайтару срокларын бозганда, вәкаләтле орган, субсидия кире кайтарылу срогы чыккан көннән алып, эш көннәрендә исәпләп чыгарыла торган җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

25. Субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшереп тору вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.